

Кеше тормышында озакка истә калырлык вакыйгалар бар. Аларнын берсе Атюрьево районында хөрмәтле кеше - Загидулла Абидулла улы Теркуловка сизмәстән генә 70 яшь килеп житте.

Юбилей коне, 70 яшь тулу унаеннан, Загидулла Абидулла улына бик кvп игелекле сvзләр һәм ихлас теләкләр әйтелде, чонки ул vз иленен хормәтле кешесе. “Кайда туган, шунда кирәк тә булган”, - диләр бит андыйлар турында. Загидулла абый Теркуловны матур дата белән котларга Атюрьево районы житәкчесе И.С.Гусаров һәм Большешуструй авыл жирлеге башлыгы И.А.Любушкин килделәр. Бардо розалар, матур теләкләр, ә ин моһиме - игътибар юбилярны битараф калдыра алмады, анын кvзләре дә шатлыктан балкыды, ә елмаюы Загидулла Абидулла улынын йозен бизәде.
Тvбән Пишляй авылында туган һәм vскән бу искиткеч кешенен тормышы - уч тобендә кебек. Туган авылы Тvбән Пишляй сигезьеллык, аннары Стрельниково урта мәктәбен тәмамлаганнан сон, М.Е Евсевьев исемендәге педагогия институтына физика-математика факультетына укырга керә. Диплом белән 1971 елда Усть-Рахмановка урта мәктәбенә эшкә урнаша, ә жиде елдан сон, Загидулла Абидулла улын «Восход» колхозынын партоешма секретаре итеп сайлыйлар. Аннары, карьера баскычы буенча менә ул: 1988 елда ана «Восход» колхозын - хужалыкны житәкләргә тәкъдим итәләр. 2005 елга кадәр, vзгәртеп кору чорында, З.А.Теркуловка икътисади планда авыр шартларда, авыл хужалыгы тармагында эшләvче кешеләр булган хужалык мәсьәләләрен хәл итәргә туры килә. Кvпме акча, хезмәт, йокысыз тоннәр һәм кvнел коче салынган. Ә 2005 елдан Загидулла Абидулла улы - авыл жирлеге башлыгы. Бу елларда да ул югары унышларга иреште: алдынгы позицияләр яулар очен vсемлекчелекне һәм терлекчелекне vстерде; кvп иттереп сот саудылар һәм ит житештерделәр, тvрәләрдән асфальт юлларынын яна километрларын “суырып алды”, кvперләр һәм  сувткәргеч челтәрләре тозеде, кондәлек мәсьәләләрне хәл итте. Ә алар бик кvп булды, чонки һәр авыл кешесенен vз язмышы.
Загидулла Абидулла улы Теркулов яхшы һәм жаваплы житәкче генә тvгел, искиткеч ир һәм әти дә, биш оныклары очен карт әти дә. Хатыны Наилә Хосәен кызы белән 50 ел бер-берсенә карата мәхәббәт, бер-берсенә карата хормәт белән яшиләр. Ирле-хатынлы

ике улларын - Шамиль белән Русланны тәрбияләп vстергәннәр. Шамильләре гаиләсе белән Торбеево авылында яши, Алтынчы ФКУИКта эшли, подполковник исеменә ия. Ә Русланнары - Мәскәvдә, белгечлеге буенча «Горводоканал»да инженер булып хезмәт итә. Алар әти-әниләренә аерым хөрмәт белән карыйлар; еш кына киләләр, булышалар. Ә жәен, әтисе vтенече буенча, машинада ботен тирә-юньне йореп чыгалар. Ул теге яки бу басудан нинди уныш жыйганын, кvпме савым сыерлары котvе булуын әле дә хәтерли... һәм мәктәп иншаларында язылганча: хатирәләрдән арыган һәм канәгать булып, оенә кайта. Ә хезмәт ветеранынын теләге шундый: Тvбән Пишляй авыллары чәчәк атсын, якташлары тыныч яшәсен, басулар чәчелсен һәм унышлар да соендерсен. Ул бит кече Ватанынын лаеклы улы.

Яхшылыкка ышану Загидулла Абидулла улыннан китми. Анын, кыенлыкларга карамастан, тормыш энергиясе, позитивлылыгы сокландыргыч. Ул, озак еллар эшләргә туры килгән кешеләр белән элемтәне югалтмый. Без дә, хормәтле Загидулла Абидулла улына, сәламәтлек, кvнелләрегезне соендергән якты иртәнге таннар, дусларыгыз һәм йортыгызда яхшы һава торышы телибез. Сезнен юбилей - зирәклек, тормыш тәжрибәсе һәм vз-vзенне раслау яше.

Н.ХӘЛИЛ